ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
2024 елда Яңа Иванаево авылында үзара салым кертү турында
Екатерина авыл җирлеге Яңа Чишмә
Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары

от 20 октябрь 2023г. № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Яңа Чишмә муниципаль районы Екатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылында гражданнар җыены нигезендә

РЕШИЛ:

1.Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Екатерина авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан,контракт буенча хәрби хезмәт үтүче Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрбиләре, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда үзара салым салуны 600 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;
-су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр).

3. Халык җыенының нәтиҗәләрен информационатерина авыл җирлегенең Яңа Иванаево авылы мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://novosheshminsk.tatar.ru/, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда: (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Екатерина авыл җирлеге башлыгы
Яңа Чишмә муниципаль районы О. В. Смурыгина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЕКАТЕРИНИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ ЕКАТЕРИНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
р 05-12005/14